ЯКШӘМБЕ
14 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 11 (5811)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ПАРТИЯГӘ КАБУЛ ИТҮ ЭШЕНӘ ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕ КӨЧӘЙТИК

Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) партиясе—ССР Союзы эшчеләр сыйнфының оешкан алдынгы отряды, аның җитәкче ядросы. Партиябез үзенең оешканлыгы белән, барлык коммунистларның фикер һәм хәрәкәт бердәмлеге белән, партиясезләр массасы алдындагы чиксез зур авторитеты белән көчле. „Безнең партиябезнең көч чыганагы, аның бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмиятле җиңүләре чыганагы шуннан гыйбарәт ки, ул, оппортунистларга, эшчеләр сыйнфының барлык дошманнарына карата килешмәүчән, яңа, ленинчел-сталинчыл типтагы партия. Безнең партиябез социаль революция партиясе, Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин теориясенең ныклы базасында үскән партия. Аның программасы һәм тактикасы, оештыру принциплары марксизм-ленинизмның гранит нигезенә нигезләнәләр. Аның сафларында—эшчеләр сыйнфының иң яхшы вәкилләре, аның иң бирелгән, иң аңлы, революцион, кыю, дисциплиналы уллары“ (Жданов).

Партиябез совет халкының иң яхшы кешеләре хисабына үсә. Социалистик Ватаныбызның меңнәрчә патриотлары—эшчеләрнең, колхозчыларның һәм совет интеллигенциясенең алдынгы вәкилләре—бөек Ленин—Сталин партиясенең члены булырга, аның сафларында коммунизм өчен алдынгы көрәшче булырга омтылалар. Партиябезнең XVIII нче съездыннан соң ВКП(б) сафлары аеруча нык үсте һәм үсә. 1939 нчы елның 1 нче мартыннан 1 нче декабренә кадәр партиянең Татарстан оешмасы ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 10.908 кеше һәм ВКП(б) члены итеп 4.149 кеше кабул итте. Бу саннар партиянең оешу ягыннан тагын да ныгуын, хезмәт ияләренең политик аңлылыгы гаять нык үсүен, миллионнарча партиясезләр массасы белән партиянең элемтәсе көчәюен күрсәтәләр.

Большевиклар партиясе үзенең составын яхшырту турында һәр вакыт кайгырта. Иптәш Сталин 1921 нче елның 6 нчы июлендә Грузия коммунистлар партиясенең гомуми җыелышында сөйләгән докладында: „Партиянең, бигрәк тә коммунистлар партиясенең көче һәм үлчәве членнарның саныннан бигрәк аларның сыйфатына, аларның ныклыгына һәм пролетариат эшенә чын күңелдән бирелгән булуларына бәйләнгәнлекне һәр вакыт хәтердә тотарга кирәк“ диде. Большевиклар партиясе сан артыннан кумый, бәлки барыннан да элек, партия сафларын коммунизм өчен көрәштә сыналган иң яхшы кешеләр хисабына үстерүне һәм ныгытуны күздә тота.

ВКП(б) Үзәк Комитеты 1939 нчы елның 16 нчы ноябрьдә чыгарган карарында, партиягә кабул итү эшенә җитәкчелек итүдә күп кенә партоешмаларның зур җитешсезлекләре булуын күрсәтеп үтте. ВКП(б) сафларына кабул иткәндә индивидуаль сайлап алу принципын бозу, оешманы иң яхшы һәм алдынгы кешеләр исәбенә үстерүгә җидди игтибар итмәү фактлары бар. Мондый кимчелекләр партиянең Татарстан оешмасында да юк түгел. Мәсәлән, Беренче Май райкомы 1939 нчы елның сентябрендә Е. дигән берәүне партиягә кабул итә һәм шуннан соң 3 айда үтми ул партиягә ялгыш кабул ителгәнлектән чыгарыла. Шул ук райком тагын М. дигән берәүне партиягә кабул итә һәм бераз вакыттан соң аның ике йөзле булуы, яла ягучы икәнлеге беленә. Апас райкомы үткән елның февраль аенда А. дигән берәүне партия членлыгына кандидат итеп кабул итә һәм 3 айдан соң ул „дәүләтне һәм колхозчыларны алдавы өчен“ партиядән чыгарыла. Ленин районында Кинопленка фабрикасы партоешмасы М. дигән берәүне ныклап тикшермичә партиягә кабул итә. Райкомда тикшерә башлагач аның партия өчен лаеклы кеше түгеллеге фаш ителә. Менә бу фактлар кайбер партоешмаларның һәм райкомнарның кешеләрне алдан ныклап өйрәнмәүләрен, ашыгуларын, индивидуаль сайлап алу принципын бозуларын күрсәтәләр. Шуның нәтиҗәсендә партиягә лаеклы булмаганнарны, чит һәм очраклы элементларны кабул итү фактлары килеп чыга.

ВКП(б) Үзәк Комитеты барлык партоешмаларны бу җаваплы эштә Сталинчыл принципны һәр вакыт дөрес һәм төгәл үтәргә мәҗбүр итә. Партоешмалар мондый ялгышларны кабатламау өчен Үзәк Комитет карарыннан үзләренә практик нәтиҗәләрне ясарга тиешләр.

Партия сафларына кабул итү эшендә ялгышлар җибәрүче башлангыч партоешмаларга райкомнар теге яки бу кешенең ВКП(б) га ни өчен кабул ителмәвен аңлатырга һәм мәсьәләне дөрес хәл итү юлларын өйрәтергә бурычлылар. Ләкин кайбер райкомнар моңа җидди әһәмият бирмиләр. Мәсәлән, Балтач райкомы үткән елның икенче яртысында партиягә кабул итү мәсьәләсе буенча 8 кешенең гаризасын кире каккан, ә кире кагуның сәбәпләре турында башлангыч партоешмаларга аңлатылмаган.

Партиягә керүчеләргә рекомендация бирү зур җаваплылык таләп итә. Ләкин кайбер урыннарда рекомендация мәсьәләсендә ВКП(б) уставын бозу фактлары очрый. Сарман районы, Карамалы МТС ы янындагы партоешма Г. иптәшкә бирелгән рекомендациянең дөреслеген тикшермичә аны партиягә кабул иткән. Фактта исә рекомендация бирүче ул кешене 8 ай гына белүе маглүм булган. Дөбъяз районында спиртзавод партоешмасы Сычов һәм Моисеев иптәшләрне икешәр рекомендация белән генә кабул иткән. Партиягә кабул итү эшенә җиңел һәм җавапсыз карашны ахрынача бетерергә кирәк.

Партиянең XVIII нче съезды ВКП(б) га кабул итү мәсьәләсендә категорияләрне бетерде. Кайбер партоешмалар съездның бу турыдагы карарыннан ялгыш нәтиҗә ясыйлар: оешманың кемнәр исәбенә ничек үсүен күздә тотып эш итмиләр, партоешма составын регулярләштерү эше белән тиешенчә шөгылләнмиләр. Шуның нәтиҗәсендә кайбер предприятиеләрдә ВКП(б) га алынучылар арасында төп профессия эшчеләре, ә авыл районнарында тракторчылар, комбайнчылар, укытучылар һәм агрономнар бик аз. Бу хәл шәһәрнең һәм авылның иң алдынгы кешеләрен партиягә сайлап алуга җидди игтибар итмәү нәтиҗәсендә килеп чыга. Партия оешмаларының җитәкчеләре предприятиенең, МТС ның, авылның, культура учреждениеләренең хәл иткеч тармакларында эшләүчеләрнең иң алдынгыларын партиягә тагын да активрак сайлап алуны оештырырга тиешләр.

Партия сафларына кабул итү—зур җаваплы эш. Партоешмаларның бурычы—партиягә кабул итү эшенә көндәлек җитәкчелек итү, ВКП(б) Үзәк Комитетының күрсәтмәләрен тулы һәм төгәл үтәүне тәэмин итү.

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ „СЕДОВ“ ЯНЫНА КИЛЕП ҖИТТЕ

13 нче гыйнварда Төньяк Диңгез Юлы Баш Идарәсе иптәш Папаниннан түбәндәге телеграмманы алды:

„13 нче гыйнварда 12 сәгат 7 минутта „И. Сталин“ бозваткычы „Георгий Седов“ бозваткыч пороходы борты янына килеп җитте. Заданиенең беренче өлеше үтәлүе турында ВКП(б) Үзәк Комитетына—иптәш Сталинга һәм СССР Совнаркомына—иптәш Молотовка хәбәр итегез.

Папанин“.

* * *

„И. Сталин“ бозваткычы борты, 13 гыйнвар. (Радио, ТАСС). Бүген иртән 7 сәгаттә „И. Сталин“ бозваткычы зур бозлар арасындагы ярыклардан файдаланып, янадан седовчыларга таба бара башлады. 12 сәгат 07 минутта бозваткыч „Седов“ борты янына килеп җитте. Седовчылар барсы да сәламәт.

Алар безнең бозваткычыбызның якынлашуын бөек Сталин хөрмәтенә шатлыклы „ура“ кычкырып каршы алдылар.

Тантаналы митинг булды. Седовчылар исеменнән бозваткычның капитаны иптәш К. С. Бадигин чыгыш ясады. Ул, бары тик социализм илендә генә кешенең тормышына югары бәя бирелүе турында сөйләде. Бары тик большевиклар партиясе һәм безнең бөек Сталин җитәкчелек итә торган Советлар илендә генә кешеләр турында гаять зур кайгыртучанлык күрсәтелә. Седовчылар бу мәхәббәтне һәм кайгыртучанлыкны һәр вакытта да хис иттеләр. Алар бер вакытта да ялгыз булмадылар. Седовчылар үзләренең беренче мәхәббәт һәм рәхмәт сүзләрен туганыбыз Иосиф Виссарионович Сталинга юнәлдерәләр.

И. Папанин.

СОВЕТ ФӘНЕНЕҢ ДАНЫ ӨЧЕН

„Седов“ның хәрәкәте—Төньяк Боз океанында өченче тарихи хәрәкәт. „Седов“ның батыр экипажы ике елдан артык вакыт буена үзенең күзәтүләрен системалы рәвештә алып барды. Боз океанының әлегә кадәр беленмәгән районнары турында ул географияне яңа белемнәр белән баетты. Хәтта бу күзәтүләр турында кыска радиограммалардан хәзергә без белгән аз гына маглүматлар да экспедициянең гаять бай фәнни багаж белән кайтуы турында җитәрлек дәрәҗәдә ышандырырлык сөйлиләр.

Котып бассейны тирәнлекләренең ничек урнашканлыгын, материкларның сай сулы киң читләре белән әйләндереп алынган океан чокырларының тирәнлек чикләре кайда икәнлекне, диңгез бозлары хәрәкәтенең картинасы нинди булуны география әле тулысынча белми иде.

„Седов“ның хәрәкәте бу мәсьәләләрне хәл итү өчен күп эшләде. Хәрәкәтнең көнчыгыш өлешендә су сайлыгы чикләре ачыкландырылды (ә бу чикләр, бигрәк тә Арктиканың Азия һәм Америка секторларында, бик аз пунктларда гына билгеле иде). Көнчыгыш озынлыкның 38 һәм 45 нче градуслары арасында 85—86 нчы градуслар киңлегендә тирәнлекнең 4.900—5.180 метр икәнлеге беленде. Бу тирәнлек котып бассейнының бу яртысында әлегәчә билгеле булган тирәнлекләрдән шактый артык.

„Седов“ның хәрәкәт юнәлешенә һәм тизлегенә ясалган анализ совет галимнәренә бозлар хәрәкәтенең һава басымы бүленешенә бәйле булуын беренче тапкыр билгеләргә мөмкинлек бирде. Хәзер бозлар хәрәкәтенең юнәлешен алдан әйтергә була. Арктикада карабларның йөрешләре өчен бу бик әһәмиятле.

„Седов“ның хәрәкәт юлының (хәрәкәтнең көнбатыш өлешендә) кайбер урыннарда Нансен экспедициясенең атаклы карабы „Фрам“ның хәрәкәт линиясен кисеп үтүе дә бик әһәмиятле.

Соңгы 20 ел эчендә Арктикада шактый гына җылыну барлыгы да билгеле. Һава һәм су температурасын, диңгез бозларының калынлыгын „Седов“ экспедициясенең күзәтүләре бу җылынуның күләмнәрен билгеләргә мөмкинлек бирә торган бердән-бер материаллар бирделәр. „Седов“ның һәм „Фрам“ның хәрәкәт көннәрендә алынган гидрология маглүматларын чагыштыру Төньяк Боз һәм Атлантик океаннарының үзара су алмашулары соңгы кырык елда көчле рәвештә артканлыкны билгеләргә мөмкинлек бирде. Билгеле бер тирәнлектә Котып бассейнына агып килә торган җылы Атлантика сулары, моннан 44 ел элек булганга караганда хәзер күбрәк күләмнәрдә киләләр. Үз чиратында Боз океаныннан котып бозларының Гренландия диңгезенә хәрәкәт тизлеге дә артты. Бу бозларның калынлыгы исә ике тапкыр чамасы кимеде.

Бу хәлләр—соңгы 25 ел эчендә җирнең һәр урында диярлек күренә торган һәм һаваның гомуми әйләнүе көчәюгә бәйләнгән климат һәм гидрология шартларының үзгәрү күренешләреннән берсе.

Седовчылар гравиметрия, магнитизм һәм башкалар буенча гаять кыйммәтле байтак материаллар алып кайталар.

Героик седовчылар совет фәне тарихына данлыклы сәхифә яздылар.

Академик А. А. ГРИГОРЬЕВ.
СССР Фәннәр Академиясенең география институты директоры



8 нче гыйнвар, 10 сәгат 45 минутта Москва шәһәре аэродромы аэропортыннан Москва—Берлин һава юлы буенча „ДС—3“ самолеты беренче сынау очышы ясады. РӘСЕМДӘ: „ДС—3“ самолеты очып китү алдыннан.
М. Рунэ фотосы (ТАСС фото-клишесе).

Англия—Франция блогының яңа сугыш учаклары булдырырга маташулары турында Германия матбугаты

БЕРЛИН, 12 гыйнвар. (ТАСС). „Кельнише цейтунг“ газетасы Англия—Франциянең төньякта сугыш уты кабызырга маташулары турында мәкалә белән чыкты.

Газета түбәндәгечә яза: „Англия белән Франция, Швецияне һәм Норвегияне Финляндиягә киң „ярдәм“ күрсәтергә мәҗбүр итәргә тырышып, аларга көчле басым ясыйлар. Англия белән Франция Скандинавиядәге һәр ике дәүләтнең Финляндиягә „ярдәмгә“ үз сугыш кораллары белән, ягни Швеция һәм Норвегия сугыш кораллары белән чыгуларына ирешмәкче булалар.

Англия һәм Франциянең чакыруларында һәм тырышлыкларында нинди чын сәбәпләрнең яшеренгәнлеге билгеле. Англия һәм Франция файдасына ясалган һәр төрле ташлама, мәсәлән, үз территорияләрендә хәрби терәк пунктлар бирү,—ди газета,—нейтралитетның бозылуын күрсәтә. Бу нәрсә Швеция белән Норвегия өчен ачык булырга тиеш. Женева йөкләмәсе дип йөртелә торган нәрсәне (Маннергейм Финляндиясенә ярдәм турында) үтәү исә Швециянең һәм Норвегиянең Германия һәм Советлар Союзы белән мөнәсәбәтләрен өзәчәк. Ул вакытта, Англия белән Франция командасындагы Милләтләр Лигасында торуны дәвам иттерүнең чын нейтралитет белән бергә сыеша алмавы ачык булачак.

Финляндиянең язмышы,—ди газета,—Англияне һәм Францияне борчымый, бу хәл һәр кемгә билгеле. Аларның (Англия һәм Франциянең) „ярдәмнәре“ тик бер генә теләкне күздә тота, ул теләк—Швеция белән Норвегияне сугышка тарту юлы белән Германиягә зарар китерү һәм барыннан да элек Германия өчен Швециядән руда чыгаруга комачаулау. Газета, бу эш Германия дошманнарына ярдәм итү һәм нейтралитетны бозу дигән сүз, дип аеруча күрсәтеп үтә.

Англия белән Франция бөтен көчләре белән сугышның яңа плацдармын булдырырга маташалар. Газета, шуның белән бергә, Франция полковнигы Фабриның сүзләренә таяна. Фабри нейтраль илләрнең Финляндияне сугыш учагына әйләндерү өчен кирәкле булган барлык шартларны—Англия һәм Франция шартларын һич сүзсез үтәүләрен таләп итә.

„Гамбургер Фремденблат“ газетасының Женева хәбәрчесе, Финляндиягә „ярдәм“ турындагы сүзләр астында Англия белән Франция нейтраль илләрне үз якларына тартырга (бу илләрдә Германия куркыныч тудыра имеш) һәм төньяк илләрдә үзләренең хәрби терәк пунктларын булдырырга маташалар.

Шулай итеп,—ди хәбәрче,—Парижда „тыныч халыкларның акрынлап төзелеп килә торган блогы“ дип йөртелә торган нәрсә—ул, чын мәгънәсендә, нейтраль илләрнең Германиягә каршы фронтын төзү теләге белән көнбатыш дәүләтләрнең яңа омтылышыннан башка нәрсә түгел. Милләтләр Лигасы да шушы теләкләргә хезмәт итә. Англия белән Франция,—нейтраль илләр экономика өлкәсендә зур артыклыклар алачаклар, дигән вәгъдә белән бу блокка, шушы нейтраль илләрне алдап кертергә маташалар.

ЯПОНИЯДӘ ЭЧКЕ ПОЛИТИК ХӘЛ

ТОКИО, 10 гыйнвар. (ТАСС). Япония газеталары эчке хәлнең кискен булуына зур игтибар бирүне дәвам иттерәләр. Газеталар, иң якын көннәрдә Абэ кабинетының отставкасы котылгысыз, дип күрсәтәләр. Газеталарның язуына караганда, соңгы көннәрдә Абэ үзенең карашын үзгәрткән һәм отставкага чыгу ягындарак тора.

„Асахи“ газетасы болай яза: „Премьер белән хәрби министр Хата арасында булган икенче беседадан соң премьер үзенең позициясен үзгәртте, чөнки армия кабинетны якламады. Абэның әле ачык җавап биргәне юк, ләкин ул отставканың котылгысыз икәнлеге турындагы нәтиҗәгә килгән булса кирәк. Аның настроениесе кабинетның барлык членнарына белдерелде“. Газета, „Политик үзгәрешләр мәсьәләсе буенча кискен сүз хәрби министр Хатада кала, ул армиянең төгәл фикрен премьерга әйтергә тиеш“ ди.

9 нчы гыйнварда Хата хәрби министрлек лидерлары белән киңәшкән. Бу киңәшмәдә ул Абэ кабинетының хәле турындагы мәсьәләдә армиянең төгәл позициясен маглүм иткән. „Асахи“ газетасы болай яза: „Кытай проблемасын хәл итүгә бөтен игтибарны тупларга кирәк булган шартларда армия политик тынычсызлык хәленә озак түзеп тора алмый. Әгәр дә Абэ инициатива күрсәтмәсә, ул вакытта армия политик үзгәрешләргә үзенең ризалыгын белдерәчәк“.

Шуның белән бер үк вакытта „Кокумин“ газетасы югары политик даирәләрнең актив эш алып баруларын күрсәтеп үтә. Бу даирәләрдә инде киләчәк кабинетның премьеры постына кандидатура күрсәтүгә хәзерлек алып барыла. Беренче вариант буенча кандидат итеп Коноэ күрсәтелә. Аңарга „көчле кабинет“ төзергә мөмкинлек биреләчәк. Ләкин Коноэ үзе бу тәкдимне кабул итәргә ул кадәр зур теләк күрсәтми. Икенче вариант буенча премьерны 3 генералның берсеннән—Сугияма, Терауци һәм хәзерге хәрби министр Хата арасыннан сайларга уйланыла. Болай булган хәлдә аларның берсенә кабинетны политик партияләр белән коалиция нигезендә оештырырга мөмкинлек бирелергә уйланыла. Аннан соң газета, финанс һәм кайбер политик даирәләрдә премьерлык постына генерал Угаки кандидатурасы күрсәтелгәнлекне әйтеп үтә. „Кокумин“ газетасының сүзләренә караганда, Абэ кабинетының хәле шушы атна ахрында тәмам маглүм ителәчәк, шуннан соң политик ситуация үзгәрәчәк. Соңгы хәбәрләргә караганда, бүген Коноэ хәзерге хәл турында печать саклаучы лорд Юаса белән беседа үткәргән. „Ници-Ници“ газетасы,—Коноэ белән Юаса „хәзер килеп чыккан политик ситуацияне үзгәртү кирәклеге турында һәм илдә политик ныклык урнаштыру өчен хәзер үк чаралар билгеләү кирәклеге турында бердәм фикергә килделәр“ дип яза.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАЛАРЫ

11 нче гыйнварда Ухта һәм Реболы юнәлешләрендә разведчикларның эзләнүләре. Петрозаводск юнәлешендә разведка отрядларының хәрәкәтләре һәм Китель районында пехота частьләренең бәрелешләре. Карелия бугазында артиллерия атышуы һәм разведчикларның эзләнүләре.

Һава начар булганлыктан авиация хәрби очышлар үткәрмәде.

* * *

12 нче гыйнварда Ухта һәм Реболы юнәлешләрендә разведчикларның эзләнүләре булды. Петрозаводск юнәлешендә пехота частьләренең бәрелешләре. Карелия бугазында разведчикларның эзләнүләре һәм сирәк-сирәк артиллерия атышуы.

Безнең авиация разведка теләге белән хәрби очышлар үткәрде.

СЕДОВЧЫЛАРНЫҢ ГЕРОИК ЭШЛӘРЕ ТУРЫНДА БОЛГАРИЯ МАТБУГАТЫ

СОФИЯ, 12 гыйнвар. (ТАСС). Соңгы вакытта Болгария газеталары „Седов“ бозваткычын бозлар арасындагы пленлектән чыгару буенча „И. Сталин“ бозваткычы экспедициясенең барышын игтибар белән күзәтәләр. „Дневник“ газетасы кичә „Седов“ның фото-рәсемнәре һәм иптәш Папанинның портреты белән зур мәкалә басып чыгарды. Газета „Седов“ның бөтен юлын һәм аны Арктика бозлары арасыннан чыгару буенча барлык чараларны язып күрсәтә. Мәкаләнең ахрында газета болай ди: „Артикада „Седов“ күп санда мөһим тикшеренүләр үткәрде һәм котыпка, котып өлкәләренә яңа экспедицияләр оештыруда гаять зур әһәмияте булган күп кенә кыйммәтле яңалыклар эшләде. Бу котып карабының экипажы үзенең бозларда күп айлар буена яшәве белән һәм котып районын өйрәнүе белән чын геройлык күрсәтте. Аның кайтуы Советлар Союзының гына түгел, бәлки башка илләрнең дә фәнни даирәләрендә түземсезлек белән көтелә“.

„Зора“ газетасы үзенең „Совет котып экспедициясенең эше һәм Совет фәненең казанышлары“ дигән мәкаләсендә: „Гаять авыр котып шартларында эш алып барган седовчыларның фәнни тикшеренүләре чын батырлык булып тора“ ди. „Совет котып экспедициясенең эше,—ди газета мәкаләнең ахрында,—совет фәненең кыйммәтле казанышларын күрсәтә“.

„Седов“ бозваткычы экипажының геройлыгы турында Норвегия газетасы

ОСЛО, 11 гыйнвар. (ТАСС). „Моргенбладет“ газетасы „Седов“ бозваткычына багышланган мәкаләдә болай дип яза: „Седов“ бозваткычы бортындагы кешеләр эшләгән эш,—ул, бөтен дөнья рәхмәт әйтәчәк культура батырлыгы. Норвегия, „Фрам“ кешеләрен ничек истә тоткан булса, „Седов“ кешеләрен дә шулай истә тотар.

Героик экипаж

ЭФИР СНАЙПЕРЛАРЫ

„Седов“ бозваткычының ватан белән радио аша элемтәсен урнаштыруда Александр Полянскийның гаять зур роленә бәя биреп бетерү кыен. Седовчылар туган илнең шәһәрләрендәге һәм авылларындагы тормыш турында радио аша белеп тордылар.

Полянский „Седов“ бортына 1936 нчы елны күчә. Бу вакытта инде ул радио элемтәсенең данлыклы мастеры, „Эфир снайперы“ иде. Беренче көннәреннән үк ул бөтен экипажда авторитет һәм мәхәббәт казанды. Полянский экипажга бик нык күнекте һәм 1938 нче елның августында аңа әгәр теләсә „Седов“ тан „Ермак“ка күчәргә тәкдим иткәч ул моннан кискен рәвештә баш тартты.

***

Легендар хәрәкәт турындагы күп санлы хәбәрләрнең авторын—Николай Михайлович Бекасовны һәр кем яхшы белә. Өлкән радист иптәш Полянский белән берлектә ул „Седов“ның радиорубкасында тәүлекләр буе дежурлык итте һәм Зур Җир белән тәртипле элемтә тотты, координатлар турында күп санлы сводкалар, бозның торышы турында мәглүматлар, фәнни эшләр турында белдерүләр тапшырды, туган җирдән хәбәрләр кабул итте. 8 ай эчендә генә дә — 1938 нче елның сентябреннән 1939 нчы елның маена кадәр — ул иптәш Полянский белән берлектә 4.400 телеграмма — 168 мең чамасы сүз тапшырды һәм кабул итте!

Николай Михайлович Бекасовка ноябрь аенда 26 яшь тулды. Аны диңгез эше кызыктыра. Ул Ленинградтагы диңгез техникумының радио бүлегенә керә һәм 1937 нче елны укуын тәмам итә. 1938 нче елның җәендә „Ермак“ бозваткычының радисты булып Бекасов Ерак Арктикага китә. Бу карабтан ул „Седов“ радиорубкасына күчә. Бу радиорубкадан ул хәрәкәтнең соңгы көннәрендә үзенең туганнарына һәм дусларына түбәндәге шатлыклы радиограмманы тапшыра:

—Өйгә кайтабыз. Тиздән барыгызны да күрәчәгемә һәм кочаклаячагыма шатланам. Безнең, седовчыларның, партия һәм хөкүмәт заданиесен, бөек Сталин заданиесен үти алганлыгыбызга шатланам.

ТИКШЕРЕНҮЧЕ БАТЫР ГАЛИМ

Тиңдәше булмаган хәрәкәт көннәрендә „Седов“ коллективы гаять зур фәнни тикшеренү эше алып бара. Яшь галим—комсомолец Виктор Харлампиевич Буйницкий бу эшнең җаны, күп кенә кызыклы күзәтүләрнең инициаторы була.

„Садко“ бозваткычы көнчыгышка таба бара. Иптәш Буйницкий үзенең фәнни эшләрен башта шунда үткәрә. Буйницкий беренче тапкыр буларак, Генриетта атавының магнит съемкасын ясый. Де—Лонг экспедициясеннән соң монда бер кемнең дә булганы юк иде. Шушы атауда ук ул җир магнетизмы элементларын билгеле һәм моның өчен гөмбәзсыман боз тавына кыен поход ясый. Буйницкий Жаннета, Беннетта һәм Жохов атауларында күп кенә фәнни күзәтүләр үткәрә.

Судноларны бозлар алып киткәннән соң эш аеруча кыенлаша. Буйницкийга күзәтү һәм тикшерү эшләрен 40 градус салкында һәм ачы җилләрдә алып барырга туры килә.

„Седов“та ул алдынгы совет фәненә гаять зур хәзинә булган кыйммәтле эшне бик яхшы оештыра һәм аңа җитәкчелек итә.

НЫКЛЫК ҺӘМ КИСКЕНЛЕК

„Седов“ бозваткычының икенче механигы Сергей Дмитрович Токаревка пароходлар һәм су юллары бала вактыннан ук таныш булалар. Ул 1906 нчы елны Волга буенда, Вольск шәһәрендә эшче семьясендә туа. 1923 нче елга кадәр иптәш Токарев Вольскидагы һәм Костромадагы балалар йортларында тәрбияләнә...

1928 нче елның көзендә Сергей Токарев Хәрби Диңгез Флотына чакырыла.

Армиядән кайтканнан соң, 1931 нче елны Токарев Архангельскийгә күчә һәм „Ленин“ бозваткычына машинист булып керә. 1936 нчы елның октябрендә ул „Седов“ бозваткычында өлкән машинист булып эшли башлый, аннан аны „Садко“га күчерәләр. „Ермак“ „Садко“ны һәм „Малыгин“ны бозлар пленлегеннән азат иткәч, Токарев һичбер икеләнмичә „Седов“ка күчә. Герой механик үзенең язмышын хәрәкәттәге судно белән озак айларга бәйли, ныклык һәм кискенлек күрсәтә, җиңүле максатка ирешергә омтыла.

КАПИТАН—БОЛЬШЕВИК

— Мин „Седов“ бортыннан аның йөзүе тәмам булганнан соң гына һәм ул совет портына килеп туктаганнан соң гына төшәчәкмен!

1938 нче елның августында хәрәкәттәге карабның капитаны Константин Сергеевич Бадигин алмашынырга тәкдим итүгә әнә шулай дип җавап бирде. Үз ватанының ялкынлы патриоты коммунист Бадигин өчен бу лаеклы җавап бик характерлы.

Константин Сергеевич Бадигин 1910 нчы елны Пензада, крестьяннәр арасыннан чыккан агроном семьясендә туган.

Бала вактыннан ук булган хиалын тормышка ашыру йөзеннән Константин Бадигин 1928 нче елны ВЛКСМ Үзәк Комитеты путевкасы буенча Фрунзе исемендәге хәрби диңгез училищесенә керә, ләкин семья хәле буенча укуын өзеп, „Красный водник“ фабрикасына такелажник булып керә.

Фабрикада ул Ерак Көнчыгыш моряклары белән таныша. Алар аны диңгездә еракка йөзүләр турында сөйләүләре белән кызыктыралар. Бадигин, яңа дуслары белән киңәшеп, Владивостокка күчә. 1929 нчы елны аны „Индигирка“ пароходына икенче класс матросы итеп алалар.

Яшь моряк карабка тиз ияләшә, командирның заданиесен бик яхшы итеп үти. Ул күңел биреп укуга керешә һәм Владивосток диңгез техникумының икенче курсына имтихан тапшыруга үзлегеннән хәзерләнә. Үз алдына куелган максатка ныклык белән ирешә барып, Бадигин 1932 нче елны беренчеләрнең берсе булып техникумны тәмам итә. Шул ук елны ул ВКП(б) сафларына керә.

Штурманлык эшендә белемен арттыра барып, иптәш Бадигин төрле лесовозларда һәм танкерларда йөри. Ул кайда гына булмады. Ул Һинд океаны дулкыннарын да, ташкынлы Бискай заливын да күрде, Сингапурда, Гамбургта, Роттердамда, Лондонда булды...

1937 нче елның язынннан Константин Сергеевичны „Садко“ бозваткычына өлкән ярдәмче итеп күчерәләр.

Көз көне „Садко“ ны „Седов“ һәм „Малыгин“ белән берлектә бозлар кыса, ә яз көне, „Седов“ның авыру капитанын самолет белән хәрәкәттәге карабтан алып киткәч, Константин Сергеевичны „Седов“ның командиры итеп билгелиләр.

ПАРТИЯ ОЕШТЫРУЧЫСЫ

„Седов“ бозваткычының помполиты һәм өлкән механигы Дмитрий Григорьевич Трофимов карабта хезмәт итүен 1924 нче елны 18 яшендә вактында башлый. Үзенең туган шәһәре Сретенскида (Чита өлкәсе) 7 еллык тимер юл мәктәбен тәмам иткәннән соң ул—депо эшчесе улы—Амур бассейны пароходында матрос булып эшли.

1929 нчы елны Трофимов Благовещенскидагы су юлы техникумына керә һәм озак та үтми аннан Тын океан сәүдә флотына күчә. Диңгездә үзенең беренче рейсен ул „Волна“ пароходында кочегар булып башлый.

1931 нче елны Трофимов—„Томск“ пароходының кочегары. Шул ук елны ул партиягә керә. 1932 нче елны Дмитрий Трофимов „Красный партизан“ һәм „Сучан“ пароходларында машинист булып эшли. Тын океан флоты карабларында ул чит ил портларында була, тропика эсселеген һәм Арктика диңгезләренең салкынлыгын татый. „Сучан“ да вакытта ук инде Трофимов гаять зур эш алып бара—коммунистлар оешмасына җитәкчелек итә.

Производство алдынгысы коммунист Трофимовны „Литке“ бозкискеченә җибәрәләр. Аның экипажы алдына диңгездә йөзү тарихында беренче тапкыр буларак бер навигация вакты эчендә Төньяк диңгез юлын көнчыгыштан көнбатышка таба үтү бурычы куелган була.

Дмитрий Трофимов бу тарихи рейстә кочегарлар старшинасы булып катнаша. Ул монда да партия оешмасына җитәкчелек итә һәм эшкә коммунистларча карау үрнәге күрсәтә. Трофимовның кочегарлар вахтасы карабта алдынгы була.

„Литке“нең алдынгылары Советлар Союзы орденнары белән бүләкләнәләр. Алар арасында Дмитрий Григорьевич Трофимов та була. Ул „Хезмәт Кызыл байрагы“ ордены ала.

Аны „Ермак“ бозваткычына дүртенче механик итеп күчерәләр. Трофимов „Ермак“та папанинчылар янына бара, хәрәкәттәге суднолар караваны янына таба булган гүзәл рейстә катнаша. „Ермак“ коллективы Трофимовны „Седов“ бозваткычына җибәрә.

„Седов“ та Дмитрий Григорьевич гаять зур эш алып бара, кыенлыкларга каршы һәм хәрәкәтне уңышлы тәмам итү өчен көрәшкә бозваткычның коллективын большевикларча туплый.

„ЭКИПАЖ САУ-СӘЛАМӘТ“

„Седов“ бозваткычыннан Зур Җиргә алына торган радиограммалар һәр вакыт:

— Экипаж сау-сәламәт,—дигән сүзләр белән тәмам була иде.

Экипажның сәламәт һәм күтәренке күңелле булуы—шактый дәрәҗәдә судно врачы Александр Петрович Соболевскийның үз-үзен аямыйча тырышлык күрсәтүенең нәтиҗәсе.

Доктор Соболевский седовчыларның сәламәтлегенә, эш сәләтлегенә һәм шатлыклы тормышларына йогынты ясый алырлык барлык нәрсәләргә төшенә.

Докторның үзенең иптәшләрен күп тапкырлар үлем тырнагыннан коткарып калу вакыйгаләрен „Седов“ экипажы яхшы хәтерли.

Александр Петрович Соболевский бик яхшы иптәш. Аврал эшләрендә аны һәр вакыт күрергә мөмкин. Кулына көрәк, балта тотып ул иң куркынычлы участокларда эшли. Буш вакытларында ул иптәшләре белән үзенең белемнәрен уртаклаша. „Седов“ моряклары гомуми белем дәресләре укыту аның иң сөекле эше була.

Александр Петрович Соболевский Белоруссия ССР ның Городок шәһәрендә туган. Шунда ук ул башлангыч белем алган.

1920 нче елны Александр Соболевский профтехника училищесенә керә һәм аны 1924 нче елны уңышлы тәмам итә. Аннары чик буе частьләренең берсендә хезмәт итә, медицина институтында укый, Төньяк диңгез юлы баш идарәсенең гидрография идарәсендә эшли. Аннары аны „Седов“ка зур гидрография экспедициясенә врач хезмәтләрен башкаручы итеп билгелиләр.

КҮРНЕКЛЕ НАВИГАТОР

Андрей Георгиевич Ефремов 1908 нче елны Сретенск шәһәрендә (Чита өлкәсе) хезмәткәр семьясендә туган. Башлангыч белем алганнан соң, ул Владивостоктагы диңгез техникумына керә. Производство практикасы үткәндә, Ефремов сәүдә флоты карабында башта өйрәнчек булып, аннары матрос булып эшли башлый һәм еракка йөзүләрдә катнаша.

Кызыл Армиядә бер ел чамасы хезмәт иткәннән соң, Андрей Георгиевич Ленинградка кайта. Монда ул су юлы транспорты инженерлары институтында укый һәм 1933 нче елның июлендә диңгездә суднолар йөртү буенча инженер-педагог дипломы белән Ерак Көнчыгышка кайта.

1935 нче елның июнендә—ул „Красин“ бозваткычында капитанның икенче ярдәмчесе. Монда ул Бадигин белән очраша, аларның соңыннан Арктикада озак айлар буена бергә булу белән ныгытылган дуслыклары шушында башлана.

1937 нче елдан башлап Андрей Георгиевич Ефремов ерак Арктика экспедициясенә киткән „Малыгин“ бозваткыч пароходындагы фәнни группаның өлкән гидрографы булып күчә. „Ермак“ ярдәме белән „Малыгин“ бозлар арасыннан чыкканнан соң, Андрей Георгиевич „Седов“ бортына күчә.

КОМСОМОЛЕЦ АЛФЕРОВ

1920 нче елны, ак гвардеецлар отряды Шенкурск өязенең ерактагы авылына якынлашып килгәндә, Всеволод Алферовның анасы партизаннар янына китә һәм кулына мылтык тотып яшь совет республикасын саклый. Семьядә олы кеше булып калган 13 яшьлек Всеволод Алферов үзенең өч энесен туйдыру өчен урман кисү эшендә эшли башлый.

1928 нче елдан башлап ул диңгез флоты белән аерылгысыз рәвештә бәйләнә. Ул „Камбала“, „Навага“, „Окунь“ траулерларында һәм „Аркос“, „Мироныч“, „Сорока“, „Пушкин“ пароходларында кочегар булып эшли.

Алферов Төньяк диңгезен, аның дулкынлы киңлекләрен нык ярата. 1933 нче елның мартыннан башлап ул Арктика Флотында, башта „Сибиряков“ та, ә аннары—„Седов“ та. Ул карабны ярата, шунда үсә, машинист һәм механик квалификациясе ала.

1939 нчы елның җәендә Алферов башка механиклар белән берлектә „Седов“ның механизмнарын тикшерә һәм аларны бозлар арасыннан чыкканнан соң өзлексез эшләүгә хәзерли, бозваткычның рулен төзәтүдә бик тырышып эшли.

Бозлар арасында хәрәкәт итү көннәрендә аның өчен җидди мәктәп була. (ТАСС).

Героик бозваткыч „Георгий Седов“ командасы. Рәсемдә (сулдан уңга): беренче рәттә—капитан К. С. Бадигин, капитанның өлкән помощнигы А. Г. Ефремов, парторг һәм өлкән механик Д. Г. Трофимов, гидрограф В. Буйницкий; икенче рәттә—өлкән радист А. Полянский, радист Н. М. Бекасов, врач Соболевский, икенче механик Токарев, боцман Буторин; өченче рәттә—повар Мегер, өченче механик Алферов, машинист Шарыпов, матрос Гаманков, машинист Недзвецкий һәм кочегар Гетман иптәшләр.

ДИҢГЕЗНЕҢ БАТЫР УЛЫ

Дмитрий Прокофьевич Буторин диңгезгә, төньякка мәхәббәтне атасыннан ала.

14 яшендә вакытта ул атасы белән бергә балык һәм диңгез җәнлекләре тотарга китә. Дмитрий Буторин 8 ел буена балык һәм диңгез җәнлекләре аулый.

1927 нче елны Буторин корбастан зур бозваткыч пароходка күчә. Ул „Сибиряков“ та, „Русанов“ та, „Седов“ та йөри. Күзәтүчән моряк төньякның яңадан-яңа районнарын өйрәнә. Ул яңа походларга омтыла.

1930 нчы елны Буторин Кызыл Армиягә алына. Кызыл Армиядән кайткач 1933 нче елның мартында ул яңадан „Седов“ ка матрос булып керә.

„Седов“ ның боцманы Дмитрий Буторин—һәр эшкә оста кеше.

Хәрәкәт көннәрендә диңгезнең батыр улы—Дмитрий Прокофьевич Буторин үзен нык лы, нинди генә кыенлыкны да җиңәргә сәләтле кеше итеп күрсәтте.

АНЫ КЫЗЫЛ АРМИЯ ТӘРБИЯЛӘДЕ

Бозваткыч „Седов“ пароходының беренче класс машинисты Иосиф Маркович Недзвецкий ярлы крестьян семьясендә туган. Кызыл Армия аның тормышында күренекле роль уйнаган. Ул аңарда гүзәл сыйфатлар—куркусызлык, Ватанга мәхәббәт, кыюлык һәм батырлык тәрбияләгән. Мотористлык квалификациясен дә аңа Кызыл Армия биргән.

„Ермак“ бозваткычының Франц-Иосиф җире ярларына бик иртә рейсе көннәрендә Иосиф Маркович Недзвецкий иң яхшы стахановчы отличник дигән дан казана. „Ермак“ бу операцияне дә бик яхшы үти һәм бозлар арасына кысылган „Садко“, „Седов“ һәм „Малыгин“ бозваткыч пароходларына таба юнәлә. „Ермак“ның гүзәл походлары көннәрендә Иосиф Маркович Недзвецкий үз-үзен аямыйча геройларча эшләп, рейснең уңышлы тәгәлләнүен тәэмин итә. „Седов“ның тагын да хәрәкәт итүенең кирәклеге мәглүм булгач, ул „Ермак“тан хәрәкәттәге карабка күчә.

БЕРЕНЧЕ КЛАСС МАТРОС

Хәрәкәттәге „Седов“ бозваткычының беренче класс матросы Ефрем Иванович Гаманков Ак диңгезнең лоцманлык дистанциясендә хезмәт итүе көннәре турында уннарча эпизодларны искә төшерә ала. Бу хезмәт аны чыныктырган, батыр, омтылышлы кеше иткән.

„Ермак“ белән Ефрем Иванович бозлар арасында кышлаган „Седов“ янына бара һәм 6 батыр котыпчы белән берлектә хәрәкәттәге бозваткыч бортына күчә. Рәхимсез салкында ул гаять катлаулы фәнни күзәтүләр алып барырга ярдәм итә.

„СЕДОВ“ ТА АЛТЫ ЕЛ

Николай Сергеевич Шарыпов 1915 нче елны Архангельскийдә „Канат“ фабрикасының тимерчесе семьясендә туа. Николай Шарыпов 1933 нче елны диңгез өйрәнчекләре мәктәбен тәмам итә һәм анда машинист һәм слесарь квалификациясе ала.

Төньякта яшәү яшь морякны чыныктыра, анарда кыюлык һәм инициатива тәрбияли. Ул „Седов“ бозваткычы пароходына эшкә кергәндә инде аның төньяк диңгезләрдә йөзүдә зур тәҗрибәсе була. Хәрәкәттәге карабның героик экипажында иң яшь кешеләрдән булу белән бергә, ул иң карт седовчыларның берсе.

Шарыпов легендар бозваткычта 6 елдан артык эшли. Ул „Седов“ның машиналарын, казаннарын һәм барлык механизмнарын саклап калу өчен бөтен көчен бирде.

ПОВАР, МОРЯК, ХУДОЖНИК

Павел Власович Мегер—потомственный повар—моряк. 16 яшендә вактында ук инде ул Одессадагы йөзүчеләр составы училищесендә укый. Шушында ук ул 1929 нчы елны комсомолга керә. 1930 нчы елны иптәш Мегер училищене тәмам итә һәм Кара диңгез пароходчылыгында матрос булып, соңыннан кочегар булып эшли.

1938 нче елның июнендә иптәш Мегер Арктика Флотының иң карт бозваткычы „Ермак“ ка камбузник булып керә. Монда ул повар профессиясе ала. Бу профессия аңа „Седов“ ның гүзәл хәрәкәте көннәрендә бик ярап куя.

Павел Власовичның тагын бер „белгечлеге“ бар: ул — талантлы художник—ял сәгатьләрендә ул үзенең альбомын „Седов“ тагы тормышны күрсәтә торган рәсемнәр белән тутыра.

КАРАБ ПИЧЛӘРЕ ЯНЫНДА

„Седов“ бозваткычын дрейфта калдырырга карар бирелгәч, „Ермак“ның иң яхшы кешеләре арасыннан хәрәкәттәге караб бортына беренче класс кочегары Иван Иванович Гетман да күчте. Тынычлык һәм куркусызлык үрнәге күрсәтеп, иптәш Гетман судноларгы һәрбер эшне бик яхшы үтәп килде.

Бу батыр кеше 1913 нче елны Нежин шәһәрендә, балта остасы семьясендә туган. Рәхимсез Арктика белән беренче тапкыр ул Шпицбергендә таныша. Бу вакытта ул совет күмер шахталарында җир казучы, грузчик, монтер булып эшли. Кызыл Армиядә ирекле булып хезмәт иткәннән соң, 1936 нчы елны комсомолец Гетман Ленинград сәүдә портында эшли, 1938 нче елның февралендә Мурманскига күчә һәм шул ук елны „Ермак“ бозваткычында төньякка—„Седов“ янына китә һәм аның белән хәрәкәттәге боз өстендә тиңдәшсез юлны үтә.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ЛЕНИН РАЙОНЫНДА ПАРТИЯ САФЛАРЫНЫҢ ҮСЕШЕ

ВКП(б) сафларына яңа членнар кабул итү мәсьәләсендә партия оешмаларыннан оешманың составы кемнәр хисабына ничек үсүен күздә тотып эшли белү таләп ителә. ВКП(б) райкомнары бу эштә үзләренең бурычларын гаризаларны карау белән генә чикләмәскә, бәлки кабул ителүчеләрнең составын өйрәнергә, партия оешмасының үсешен регулярләштерү мәсьәләсенә ныклы әһәмият бирергә тиешләр.

Ленин райкомы ВКП(б) Үзәк Комитетының бу турыдагы күрсәтмәләрен үтәү йөзеннән шактый эшләр башкарды. Партиягә кабул итү мәсьәләсендә башлангыч партоешмаларның игтибары предприятиеләрдәге төп проффессия эшчеләрен һәм техник кадрларны өйрәнүгә һәм аларның иң яхшыларын партиягә сайлап алуга юнәлтелде. Хәзер моның конкрет нәтиҗәләре күренә башлады. Партиянең XVIII нче съездыннан соң 280 кеше ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алынды. Шулар арасында эшчеләр 62 һәм инженер-техник работниклар 107 кеше исәпләнә.

Районда алдынгы хатын-кызларны партиягә кабул итү эше ВКП(б) ның XVIII нче съездына кадәр начар тора иде. Съездан соң бу эштә дә беркадәр борылыш ясалды: 39 хатын-кыз партия сафларына кабул ителде. Ләкин бу сан аз әле. Алдынгы хатын-кызларны партиягә сайлап алу эшендә райкомның җитәкчелеген тагын да ныграк көчәйтәсе бар.

ВКП(б) ның яңа уставы совет интеллигенциясенең алдынгы вәкилләренә партиягә керү мөмкинлекләрен җиңеләйтте. Шулай да әле районда алдынгы укытучыларны һәм врачларны ВКП(б) сафларына кабул итү эше йомшак бара. Укытучылардан партиягә съездан соң 6 гына кеше кабул ителде. Райком бу кимчелекне сизеп, үзенә кирәкле практик нәтиҗәне ясады: совет интеллигенциясе арасында эшләүне көчәйтү чараларын күрә.

Башлангыч партоешмаларның оештыру һәм эчке эшләренә оператив җитәкчелек итүдә райкомнарның оештыру - инструкторлык бүлекләре зур роль тоталар. Ленин районында оештыру - инструкторлык бүлеге үткән елны июль аенда оештырылды. Предприятиеләрдәге партоешмаларга практик ярдәм күрсәтү буенча ул күп кенә эшләр алып бара. ВКП(б) сафларына кабул итү мәсьәләсе турында башлангыч партоешмаларның секретарьлары белән өч тапкыр киңәшмә үткәрелде. Партиягә кабул итү эше начар торган партоешмалар белән аерым рәвештә шөгылләнелде, аларга конкрет булышлык күрсәтелде. Шуның нәтиҗәсендә, хәзер эш сизелерлек рәвештә яхшырды.

Юлбашчыбыз иптәш Сталин партия оешмалары алдына: „Партиянең составын системалы рәвештә яхшырта бару, партия членнарының аңлылык дәрәҗәсен күтәрү һәм партия сафларына индивидуаль сайлап алу тәртибендә тик сыналган һәм коммунизм эшенә чын күңелдән бирелгән иптәшләрне генә алу“ бурычын куйды.

Партиянең һәрбер оешмасы, һәрбер коммунист юлбашчыбызның бу күрсәтмәсен истә нык тотарга, партиябезнең сафларын чит һәм очраклы элементлар килеп керүдән сакларга тиеш. Кайбер башлангыч партоешмаларның җитәкчеләре бу принципны нык үзләштереп җиткермәүләре күренә: партиягә кабул ителүче һәрбер кешегә индивидуаль якын килә белмәү, аны ныклап тикшермәү фактлары очрый. Мәсәлән, Кинопленка фабрикасының партоешмасы М. иптәшне ВКП(б) членлыгына кандидат итеп кабул иткән иде. Эшне райкомда тикшерә башлагач, ул кешенең партиягә лаеклы түгеллеге беленде һәм башлангыч оешманың бу турыдагы карары юкка чыгарылды. Райком башлангыч оешмадагы коммунистларга ул ялгышның асылын аңлатты. Бу аңлату аларга тәрбияви яктан зур йогынты ясады.

ВКП(б) сафларына яңа кабул ителгән иптәшләр белән эшләү турында бернечә сүз. Аларның күбесе җәмагат эшләрендә, партия оешмасының эшендә актив катнаша. Алар партия җыелышларында кимчелекләрне тәнкыйтьләп чыгалар һәм эшлекле тәкъдимнәр кертәләр. Яшь коммунистлардан слесарь Егоров, техник Соколов, электросварщик Гыйниятуллин иптәшләр производствода һәм җәмагат эшендә аеруча яхшы инициатива күрсәтәләр. Кандидатларның күбесе „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән өйрәнәләр. Мәсәлән, инженер-электрик Есипов, плановик Хрунин, инженер Стефанов, укытучы Лисовская һәм башка күп кенә иптәшләр большевизмны өйрәнү белән системалы рәвештә шөгылләнәләр.

Районда ВКП(б) сафларын үстерү өчен резерв зур. Партиянең башлангыч оешмаларына партиясез актив белән эшләүне көчәйтергә, ВКП(б) сафларына индивидуаль сайлап алу принципын нык саклап эш итәргә генә кирәк.

Алимов.

КОЛХОЗЛАРДА ЯҢА ПАРТОЕШМАЛАР

Беренче Май районында авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан һәм авыл интеллигенциясеннән йөзләрчә иптәшләр партия сафларына керәләр. 1939 нчы елда партиянең район оешмасы ВКП(б) члены һәм кандидаты итеп 229 кешене кабул итте. Алар арасында 15 колхоз председателе, 9 тракторчы һәм комбайнчы, 6 кырчылык бригадасы бригадирлары бар.

Партиянең башлангыч оешмалары саны да үсә. Узган елны районның 20 колхозында башлангыч партоешма, 6 колхозда кандидатлар группасы оештырылды.

* * *

Партиянең Буа район оешмасында 358 коммунист исәпләнә. Алардан 211 кеше партия сафларына үткән елны кабул ителгән.

1939 нчы елны районда 9 яңа партоешма һәм 3 урында кандидатлар группалары оештырылды. Кайрево авыл советы территориясендә партиянең XVIII нче съездына кадәр бер генә коммунист бар иде, ә хәзер анда партиянең башлангыч оешмасы төзелде.

Ләкин партиянең район комитеты партия оешмаларын алдынгы колхозчылар, МТС һәм совхоз эшчеләре хисабына үстерүгә тиешенчә игтибар бирми. 1939 нчы ел дәвамында партиягә колхозчылардан 38 кеше, МТС һәм совхоз эшчеләреннән 6 гына кеше кабул ителгән. Хатын-кызлардан партия сафларына тарту эше дә начар куелган. 358 коммунист арасында 43 кенә хатын-кыз бар. Күп кенә башлангыч партоешмалар партия сафларын үстерү эше белән шөгылләнмиләр. Мәсәлән, „Кызыл Нур“, „Дружба“ колхозлары һәм райпрокуратура янындагы партоешмалар 1939 нчы елны партиягә бер кеше дә кабул итмәгәннәр.

(ТатТАСС).

Хәрәкәттәге карабта 26 ай

БОЗЛАР АТАКА БАШЛАДЫЛАР

„Седов“ ның командасы Арктиканың суык бушлыкларында вахтада нык торуында дәвам итте.

26 нчы сентябрьдә бозлар карабка атака башладылар. Пароход уң як бортка таба бик нык янтайды. Су астында калган холодильник аркылы көчле рәвештә су бәреп керә башлады. Хәл чиктән тыш кыенлашты. Трюмдагы йөкләрнең авышуы зур куркыныч тудыра иде. Экипаж боз өстенә чыгарга хәзерләнгән иде инде. Нак менә шушы куркынычлы моментта механик Токарев һәм машинист Шарыпов иптәшләр машина бүлегенә төштеләр һәм көч җитмәслек булып күренгән кыенлыкларны җиңеп, су бәреп керә торган тишекне пакле белән томаладылар. Бозларга каршы ныклы көрәш бу юлы да седовчыларның җиңүе белән тәмам булды. Ләкин яңа һәлакәтләр булу мөмкинлеге бетмәде. Һәр төрле очраклыкларга хәзерләнеп, команда пароходны туктатты, карабны яңадан боз кыса калса дип, корпусларны ныгыту өчен өстәмә айсбимслар куйды, „Седов“ тан 100 метрлар ераклыкта боз өстендә һәм пароходның палубасында ике авария базасы оештырды. Һәрбер базада азык әйберләренең, мех киемнәрнең, аяк киемнәренең 5 айлык запасы, радио станциясе һәм фәнни күзәтүләр өчен приборлар комплекты бар иде.

Бер ел эчендә „Седов“, тәүлегенә уртача 4 миль тизлек белән 1.500 миль үтте. 23 нче октябрьдә, хәрәкәтнең еллыгы көнендә, „Седов“ флаглар белән бизәлде. Куркусыз котыпчылар Сталин һәм Молотов иптәшләрдән котлау телеграммасы алдылар:

„Седов“ бозваткычы
Капитан Бадигинга,
Парторг Трофимовка

Хәрәкәтнең еллыгы көнендә сезгә һәм „Седов“ ның бөтен экипажына кайнар сәлам җибәрәбез. Юлыгызда очраган барлык кыенлыкларны совет кешеләрендә була торган большевистик ныклык белән җиңеп чыгарсыз һәм Ватанга җиңүчеләр булып кайтырсыз дип ышанабыз.

Кулларыгызны кысабыз, иптәшләр!

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Совнаркомы тапшыруы буенча

И. Сталин. В. Молотов“.

Партия һәм хөкүмәт җитәкчеләренең котлавы барлык седовчыларны тирәнтен тәэсирләндерде. Алар митингка җыелып, Сталин һәм Молотов иптәшләрнең котлавына җавап хаты кабул иттеләр, бу хатта алар кайгыртучанлык күрсәтүләре өчен аларга чын күңелдән рәхмәт әйттеләр һәм бер нинди кыенлыкның да үзләре өчен куркынычлы түгеллеген белдерделәр.

„Седов“ экипажы чиктән тыш әһәмиятле фәнни эшне үтәп, бөтен Ватаныбыз белән бер тормышта яшәде, радио аны Ватаныбыз белән ышанычлы элемтәдә тотты. Хәрәкәттәге карабта укулар барды. Седовчылар радио буенча алынган „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнделәр, үзләренең „Мы победим“ исемле стена газеталарын регуляр рәвештә чыгардылар.

1938 нче елның 14 нче ноябрендә „Седов“ төньяк киңлекнең 85 градус 39 минутына һәм көнчыгыш озынлыкның 126 градус 16 минутына җитте. Шул вакыттан башлап бозваткыч элмәк төсендә хәрәкәт итәргә керешә. 1 нче декабрьдә, көнбатыш җиле искәндә, „Седов“ көньяк-көнчыгыш юнәлештә хәрәкәт итә башлады. 13 нче декабрьдә пароход төньяк киңлекнең 84 градус 22 минутында булды. Аннары ул көньякка таба китте, көньяк-көнбатышка борылды һәм 17 нче декабрьдә „Седов“, чама белән 3 нче октябрьдә булган урынга килеп чыкты. Шулай итеп боз ваткыч көньяк-көнбатыш юнәлешенә сузылган гаять зур элмәк ясады һәм 1.150 квадрат миль чамасы мәйданны әйләнеп чыкты. 20 нче февральдә „Седов“ 86 нчы параллельне үтеп, „фрама“ рекордын узып китте һәм төньяк киңлекләрдә хәрәкәт итү буенча яңа рекорд бирде.

1939 нчы елның гыйнварында „Седов“та дүрт авыр аврал булды. Седовчылар аврал эшләрен буранда, үтә салкын җилдә һәм 45 градуслы суыкта үтәделәр.

„ХӘРӘКӘТНЕҢ АХРЫНА КАДӘР БОЗВАТКЫЧТА КАЛАБЫЗ“

Легендар бозваткыч 86 нчы параллель артында хәрәкәт итүне март ае буена дәвам иттерде. Бозлар карабны Төньяк Котыптан 440 километр төньяк көнбатыш юнәлештә алып киттеләр. Бу көннәрдә седовчылар ВКП(б) ның XVIII нче съездында Молотов һәм Жданов иптәшләрнең докладлары тезисларын радио буенча кабул иттеләр. Бөтен совет халкы белән берлектә алар большевиклар партиясенең тарихи XVIII нче съездын каршы алырга хәзерләнә башладылар.

Аларга алмашынырга тәкъдим ителгәч тә, алар хәрәкәтне ахрына кадәр дәвам иттерергә теләүләрен бердәмлек белән белдерделәр. Сталин һәм Молотов иптәшләр исменә җибәргән хатында экипаж болай дип язды:

„Кадерле Иосиф Виссарионович һәм Вячеслав Михайлович!

Төньяк Боз океаны бозлары арасында хәрәкәт итүче „Георгий Седов“ бозваткыч пароходының экипажы, Ватаныбызның бөтен бөек халкы белән берлектә, сөекле партиябезнең тарихи XVIII нче съездын каршы алырга хәзерләнә. Без, „Георгий Седов“ бозваткыч пароходы Арктика бозлары арасыннан чыкканчыга кадәр аңарда сменасыз эшләвебез данлыклы съездга безнең иң яхшы бүләгебез булыр дип карар бирдек...

Сезне, партия Үзәк Комитетын, хөкүмәтне һәм Ватаныбызның бөтен бөек халкын ышандырабыз ки, без алган йөкләмәбезне намус белән үтәрбез һәм хәрәкәтне тәгәлләп, совет фәненә кыйммәтле хәзинә кертербез, совет патриотларында була торган батырлык, түземлелек һәм геройлык үрнәкләрен күрсәтербез. Сезнең исмегез, иптәш Сталин, безнең өчен юл күрсәтүче йолдыз булып тора, бу йолдыз белән без Ватаныбызга җиңүчеләр булып кайтырбыз“.

Күп тә үтмәде седовчылар Москвадан җавап алдылар: „Хөкүмәт бозлар арасында хәрәкәт тәмам булганчыга кадәр экспедициянең бөтен составын „Седов“ та калдыру турындагы үтенечне канәгатьләндерде“.

В. И. Ленин Үзәк музеендә

Ут сүнә, күп халыклы аудиториянең сөйләшүе тына һәм тамашачыларның шатлыклы карашлары алдында, экранда, җанлы Ленин образы күренә. Без аны Беренче Май демонстрациясендә, Всеобуч парадында мәктәптән тыш белем буенча беренче съезд көннәрендә күрәбез. Халык аңа көчле рәвештә кул чаба, сөекле юлбашчының һәрбер сүзен йотлыгып тыңлаучы ун меңнәрчә кешеләр аңа кул чабалар һәм бу кул чабуларның яңгыравы Советлар иленең барлык почмакларыннан җыелган совет кешеләре утыра торган шушы музей кинозалына ишетелгәндәй була. Бөек Ленин тормышының аерым эпизодлары кинооператор тарафыннан пленкага төшерелгәннән бирле күп еллар үтте, ләкин халыкның аңа булган мәхәббәте һәр вакыт көчле һәм хәзер, Владимир Ильичның кадерле йөзен гәүдәләндерүче экранга карап торганда тамашачылар аңа шул вакыттагы кебек күп тәэсирләнеп кул чабалар.

Музейнең актыккы, егерме икенче залын карау Ленин турындагы документаль картинаны күрсәтү белән тәмам була. Ләкин музейгә килүчеләрнең күбесе барыннан да элек кинозалга омтылалар һәм экспонатлар белән танышуны планда күрсәтелгән тәртиптә шушы залдан башларга телиләр. Хәер, кинозалда ике тапкыр—музейне карый башлар алдыннан һәм барлык бүлмәләрдән йөреп чыкканнан соң булуны артыграк күрүче экскурсантлар да аз түгел.

Эшчеләр сыйнфының бөек остазлары булган Лениннең һәм Сталинның дуслыгын, аларның биографияләрендәге якынлыкны чагылдыручы кайбер фактларны күрсәтә торган документлар музейгә килүчеләрнең игтибарын үзләренә тарталар.

Иптәш Сталин Горидагы духовный училищене бик яхшы итеп тәмам иткән кебек, Ленин дә гимназияне шулай ук яхшы итеп тәмамлый. Революцион эше өчен Ленин Казан университетыннан чыгарыла; шул ук сәбәп аркасында иптәш Сталинны да Тифлис семинариясеннән чыгаралар. Аларның икесен дә патша хөкүмәте эзәрлекли, ләкин хәтта төрмәдә утырганда да алар революцион оешмалар белән элемтәләрен өзмиләр, аларга җитәкчелек итәләр, алар өчен өндәмәләр, листовкалар, прокламацияләр язалар.

Музей „Патша хөкүмәтенә“ һәм „Социал-демократик партия программасының проекты һәм аңлатмасы“ дигән исемнәр астында 1895—1896 нчы еллар чорында Владимир Ильич тарафыннан төрмәдә язылган прокламацияне күрсәтә. Шулай ук музейдә большевикларның Авлабардагы атаклы яшерен типографияләренең макеты куелган. Бу типография ул чагында төрмәдә утыручы иптәш Сталин директивасы буенча оештырылган иде. Бу типографиядә грузин, рус һәм әрмән телләрендә большевистик газеталар, Ленин һәм Сталин әсәрләре, аларның массаны үзенең азатлыгы өчен көрәшкә күтәрүче ялкынлы сүзләре басылды.

Экскурсия җитәкчесе безне бер стена янына чакыра. Анда пыяла астында „Россиядә капитализмның үсеше“ исемле китапның 1899 нчы елны басылган һәм саргаеп беткән бер томы эленеп тора. Бу китапны язарга хәзерләнгәндә Ленин гаять күп китаплар укып чыккан. Экскурсия җитәкчесе шунда ук „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ннан Лениннең бу әсәрен народниклыкны идея ягыннан тар-мар итүне тәгәлләгән иң әһәмиятле фәнни әсәр дип характерлый торган



Владимир Ильич Лениннең үлүенә 16 ел тулуга карата. РӘСЕМДӘ: Москва шәһәрендәге В. И. Ленин Үзәк музей йорты.
Э. Евзарикин фотосы (ТАСС фотохроникасы).

урынны укып күрсәтә.

Без башка залларга китәбез. Анда Лениннең үзенең әсәрләрен язган вакытта укып чыккан, төрле телләрдә басылган йөзләрчә китаплар куелган. Музейне караучылар Владимир Ильичның гаять тирән белеменә генә түгел, бәлки аның гадәттән тыш тырышлыгына һәм эшчәнлегенә дә сокланып витрина янында тын гына торалар. Бу минутларда иптәш Сталинның музей стеналарыннан берсенә язылган сүзләре хәтергә килә: „Ильичны, остазыбызны, юлбашчыбызны исегездә тотыгыз, яратыгыз, өйрәнегез“.

Без яшь Совет республикасын һәммә яктан да ак гвардеецлар һәм интервентлар китереп кыскан авыр елларда Ленин тарафыннан язылган газета мәкаләләрен, өндәмәләрне, телеграммаларны укыйбыз.

Иң авыр һәм иң кыен көннәрдә дә дошманның тәмам җиңеләчәгенә ышануларын югалтмаган һәм бу ышанычны миллионнарча кешеләрдә тәрбияләгән Лениннең һәм аның иң якын көрәштәше Сталинның иксез-чиксез оптимизмын без хәзер, күп еллар үткәч, бигрәк тә нык сизәбез. Ленин Кызыл Армия частьләренә аларны рухландырырлык сүзләр җибәрә, ул хыянәтчеләрне һәм сатлыкларны рәхимсез җәзалауны таләп итә, ул интервентларга отпор бирү өчен кешеләрне туплый, ул, Сталин белән берлектә, граждannар сугышы фронтларына җитәкчелек итә. Һәм менә шушы, иң авыр моментларда да Ленинда булган оптимизм үзенең туплау көчен безнең көннәргә кадәр саклап калды.

Иптәш Сталинның Сталинский сайлау округы сайлаучыларына сөйләгән речьennән бик матур бер урын яңадан искә төшә: безнең политик эшлеклеләребез „эш кыенлаша башлаганда һәм горизонтта нинди дә булса куркыныч гәүдәләнгәндә һәр төрле паникадан, паникага ошаган һәр төрле нәрсәдән азат булсыннар“, алар „паникага ошаган һәр төрле нәрсәдән, Ленин кебек үк, азат булсыннар“.

Без Лениннән һәм Сталиннан кыюлыкка һәм куркусызлыкка, гүзәл большевистик сыйфатларга,—дошманнар тарафыннан чолганып алынган илебезнең җиңеп чыгуына булышлык иткән сыйфатларга өйрәнергә тиешбез.

Музей 22 киң залга урнашкан һәм алар барсы да Советлар Союзының төрле районнарыннан монда килгән экскурсантлар белән тулганнар. Музей ачылганнан бирле бернечә ел эчендә анда дүрт миллионнан артык кеше булды.

Музей стеналарында Лениннең эшчеләр һәм колхозчылар белән очрашуларын күрсәтә торган уннарча матур картиналар эленеп тора. Без картиналардан гына түгел, бәлки башка документлардан да, халыкның Ленин белән никадәр якын элемтәдә булганлыгын, үзенең болай да дәүләт эше белән күмелгән булуына да карамастан, үзенә генә хас булган гадилек һәм киң күңеллелек белән, халыкның ихтыяҗларын һәм теләкләрен белеп тору өчен һәр вакытта да, халык вәкилләрен ничек еш кабул иткәнлеген күрәбез.

Владимир Ильич янында булган крестьяннәр депутациясе, үз авылына кайткannан соң, хөкүмәт башлыгының аларны ничек итеп каршы алганлыгы турында сөйләгәннәр. Крестьяннәр Лениннең ничек яшәвен һәм ничек эшләвен сораша башлаганнар. Моңа каршы депутация членнары аның кабинетының бик гади җиһазландырылганлыгын, анда күп китаплар барлыкны, үзләренең бик яхшы кабул ителгәнлекләрен, ләкин Лениннең салкын бүлмәдә эшләвен сөйләгәннәр. Шушыларны ишеткәннән соң крестьяннәр Ленингә бер вагон утын җибәрергә һәм аңа тимер пич ясап бирергә карар биргәннәр.

Бу факт балаларчарак та булсын, ләкин аның каравы ул халыкта үзенең сөекле Ильичына нинди җылы хисләр булганлыкны күрсәтә. Музейдә эшчеләрнең һәм колхозчыларның Ленингә булган игтибарларын күрсәтә торган бик күп бүләкләр куелган. Монда бик матур итеп бәйләнгән скәтерләр, фарфордан эшләнгән ченаяклар да, хрустальдән эшләнгән кара савытлары да, уннарча башка төрле әйберләр дә бар.

... Тышта караңгы төшә. Ләкин экскурсантлар агымы тукталмый. Әле хәзер генә Украинадан, Грузиядән, Уралдан яңа группалар килде. Экскурсия җитәкчесен көткән арада алар Владимир Ильичның дөньядагы 83 төрле телдә басылган әсәрләрен карыйлар. Алар бер шкафтан икенчесенә күчәләр һәм дөньяда Ленин сүзе барып җитмәгән бер генә почмак та, ихтимал, юктыр дигән карашка килеп горурланалар. Экскурсантлар истәлек төсендә язылган бик күп китапларның, матур әдәбият һәм музыка әсәрләренең, бөек юлбашчы турында балалар өчен язылган китапларның һәм биография төсендәге китапларның бай коллекциясен күрәләр.

Музейдән китәр алдыннан, Себердән килгән экскурсантлар группасы кинозалга яңадан килеп керә. Картина инде күрсәтелә башлаган. Аның икенче өлеше бара: иптәш Сталин Бөтенсоюз Советларының VIII нче Гадәттән тыш Съездында ССР Союзы Конституциясенең проекты турында доклад ясый: „Безнең кешеләребезнең нәрсә өчен көрәшкәнлекләрен һәм аларның бөтен дөнья күләмендәге тарихи җиңүләргә ничек ирешкәнлекләрен белү күңелле һәм шатлыклы. Безнең кешеләребез түккән күп канның бушка китмәгәнлеген, аның нәтиҗәләр биргәнлеген белү күңелле һәм шатлыклы“.

Съезд делегатларының көчле кул чабулары музей кинозалындагы тамашачыларның көчле кул чабулары белән бергә кушыла. Халык, Ленин мирасын саклап калган һәм күп тапкырлар арттырган Сталинны котлый. Халык, Ленин эшен бөек дәвам иттерүчене котлый.

Иң катлаулы техникалары булган гаять зур предприятиеләр, яңа шәһәрләр, мул уңыш бирүче социалистик кырлар, Ленин—Сталин партиясе тарафыннан тәрбияләнгән һәм могҗизалы, яңа тормыш төзүче героик кешеләр,—документаль кинокадрларда күрсәтелгән бу җиңүләр һәм кешеләр барсы да Ленин эшенең җиңгәнлеген тантаналы төстә раслыйлар.

И. Верховцев.

Чит илләрдә

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Кытай чыганакларыннан алынган хәбәрләргә караганда, милли хөкүмәт гаскәрләре Гуандун провинциясенең үзәк өлешендә япон частьләренә каршы үзләренең һөҗүмнәрен дәвам иттерәләр. Цунхуадан һәм Цзэнчэннән төньяктагы районда японнарның төп көчләре 9 нчы гыйнварда көньяк юнәлешендә Кантон — Коулун тимер юлына таба гомуми чигенү башладылар. Цзэнчэннең төньяк окраиналарында кытай гаскәрләре японнарның чигенүләрен каплап бара торган япон частьләре белән очраштылар.

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә кытай гаскәрләренең Наньниннан көньяк-көнчыгыштарак хәрәкәт итә торган колоннасы шушы пункттан 3 километр ераклыкта гына тора. Наньниннан төньяк-көнчыгышка таба кытай гаскәрләре, чигенеп баручы японнарны эзәрлекләгән хәлдә Саньтанны алдылар (Наньниннан 20 километрда).

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Хунань провинциясенең төньяк-көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре 8 нче гыйнварда Янлоусыда һәм Чжаолицяода (Кантон—Ханькоу тимер юлындагы станцияләр) японнарның позицияләренә атака ясадылар. Кытай гаскәрләренең бер өлеше Янлоусыга бәреп керде. Биредә кытайлар японнарның берничә складларына ут төрттеләр. Кытайлар бу станцияләр арасында, тимер юл полотнасын сүтеп, Иочжоу белән Учан арасындагы юлны кистеләр.

Хубэй провинциясенең көньяк өлешендә кытай гаскәрләре 8 нче гыйнварда Туншаньнан төньякка таба японнарның позицияләренә атака ясадылар. Японнарның 300 гә якын кешеләре үтерелде һәм яраланды. Кытай частьләре, инициативаны үз кулларында тоткан хәлдә, Чжунсяньдә (Ханькоудан төньяк-көнбатышта, Янцзы елгасы буенда) японнарның позицияләренә атакаларны дәвам иттерәләр. Кытайларның шушы ук частьләре Чжунсянь — Цзиншань—Ханькоу арасындагы шоссенең бер өлешен җимерделәр. Кытай гаскәрләре шул ук көнне Цяньцзян шәһәренә бәреп керделәр (бу шәһәр Хань һәм Янцзы елгалары очпочмагында урнашкан). Японнар урам сугышы вактында зур югалтулар бирергә мәҗбүр булдылар. Кытайлар, азык складларын яндырганнан соң, шәһәрдән чыгып киттеләр.

Шанхай—Нанкин—Ханчжоу өчпочмагында ике атна буена тынлык булып торганнан соң тагын сугышлар башланды. Путуннан (Шанхай шәһәренең бер районы) көнбатышка таба 6 нчы гыйнвардан бирле каты сугышлар бара. Кытайның 4 нче армиясенең аерым частьләре соңгы көннәрдә Шанхай бистәләренә барып җиткәннәр, дигән мәглүматлар бар.

„Даваньбао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, кытай партизаннары Цзясин станциясе тирәсендә (Шанхай—Ханьчжоу тимер юлында) японнарның гаскәри поездын шартлатканнар. Паровоз һәм 9 вагон юкка чыгарылган. Японнарның бик күп солдатлары үтерелгән. „Шуньбао“ газетасы,—10 нчы гыйнварда Сучжоу районында (Цзянсу провинциясе) кытай партизаннары япон грузовиклары колоннасын басып алдылар, дип хәбәр итә.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк өлешендә Кытай гаскәрләре, Ичэнгә һәм Сясяньгә үзләренең атакаларын дәвам иттергән хәлдә, японнарга зур зарарлар китерәләр. Чжанцыдан көньяк-көнбатыштагы районда японнар, 15 меңгә якын гаскәр туплап, актив хәрәкәт башладылар.

Франциянең социал-демократ лидерлары белән эшчеләр арасындагы элемтәнең бердән - бер төре.
В. Лисевич һәм В. Барков рәсемнәре (ТАСС фото-клишесе).

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 11 гыйнвар. Франциянең кичә кич белән игълан ителгән рәсми белдерүендә, „артиллерия атышуы, разведка частьләренең хәрәкәтләре, шулай ук авиация хәрәкәтләренең башлануы“ күрсәтелә.

Бүген иртә белән игълан ителгән белдерүдә болай диелә: „Төнлә әйтерлек бер нәрсә дә булмады. 10 нчы гыйнварда без үз позицияләребез турысында дошманның ике самолетын бәреп төшердек“.

БЕРЛИН, 11 гыйнвар. Германия армиясе верховный командованиесенең сводкасында болай диелә: „Саарбрюккеннан көньяктагы районда дошман ротасы атака башлады. Атака кире кайтарылды. Сугыш кырында дошман үзенең үтерелгән солдатларын калдырып китте. Берничә кеше пленгә алынды. Дошманның ике самолеты бәреп төшерелде. Кольмар тирәсендә Германия самолеты ватылды. Англиянең 9 бомбардировщигы Германия яры буендагы аэродромнарны икенче тапкыр бомбага тотарга маташканда Германиянең 9 самолеты тарафыннан каршы алындылар. Сугышта Англиянең өч самолеты бәреп төшерелде, дүртенчесе нык рәвештә зарарланды. Германия самолетлары үз базаларына зарарсыз кайтып керделәр“.

ЛОНДОН, 11 гыйнвар. Англиянең авиация министрлеге Англия самолетларының 10 нчы гыйнварда Төньяк диңгезеннән ерак бер урында шактый күп сандагы Германия самолетлары белән очрашканлыкларын хәбәр итә. Очрашу нәтиҗәсендә һава сугышы башланып киткән. Германиянең бер самолеты диңгезгә, икенчесе Дания территориясенә төшкән. Англиянең бер самолеты үз базасына кайтмаган.

ЛОНДОН, 11 гыйнвар. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Төньяк диңгездә Германия самолетларының бомбага тотулары нәтиҗәсендә Англиянең „Апминстэр“ пароходы батырылган. Экипаждан 3 кеше үтерелгән, 10 кеше көймәләргә утырып котылганнар.

БЕРЛИН, 11 гыйнвар. Германия информация бюросының Амстердамнан хәбәр итүенә караганда, Норвегиянең „Манкс“ пароходы минага бәрелгән һәм Оркней атауларыннан көнчыгыштарак баткан. Экипажның 7 кешесе салга утырып котылганнар.

БЕРЛИН, 11 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросы Аргентинаның „Памперо“ газетасы хәбәрен тапшыра. Бу хәбәрдә диңгез сугышы вактында Германия броненосецы „Адмирал граф Шпее“ тарафыннан нык зарарланган Англия крейсеры „Эксетер“ нең Баиа Бланкадан (Аргентина) 80 миль ераклыкта батканлыгы белдерелә. Аның экипажы француз линкоры „Дюнкерк“ бортына алынган һәм фальклэнт атауларына илтеп куелган.

БЕРЛИН, 12 гыйнвар. Германия информация бюросы түбәндәгечә хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта—җирле характерда артиллерия һәм разведка хәрәкәте. Германиянең хәрби-һава флоты Англиянең һәм Шотландиянең көнчыгыш ярлары өстендә һәм, шулай ук, Шотландия атаулары өстендә үзенең разведка очышларын дәвам иттерде. Шотландия ярлары тирәсендә Германия самолетлары Англиянең 3 сакчылык карабын һәм коралланган бер сәүдә пароходын батырдылар. Бу пароход самолетларга каршы ут ачкан иде. Шушы районда Германия самолетларының Англия истребительләре белән һава сугышы булды. Нәтиҗәдә дошманның бер самолеты бәреп төшерелде. Англия самолетлары Германия атауларының берсендә урнашкан герман аэродромнарының берсенә налет ясадылар, ләкин бер нинди зарар да китерә алмадылар“.

БЕРЛИН, 12 гыйнвар. Англиянең 7.267 тонна авырлыктагы „Элосо“ дигән танкеры тулысынча нефть йөге төягән хәлдә Англиянең көнбатыш яры буенда шартлады. Танкер Көньяк Америкага булган 6 атналык юлдан кайтып килә иде. Танкер шартлаганнан соң исән калучылар сугыш карабы тарафыннан алындылар. Экипажның 36 кешесеннән 3 се хәбәрсез югалды.

ЛОНДОН, 12 гыйнвар. Италиянең 5.123 тонна авырлыгындагы „Травиата“ пароходы минага бәрелеп батты. Пароходның 60 кешелек командасы коткарылды.

ЛОНДОН, 12 гыйнвар. Англиянең 2.719 тонна авырлыгындагы „Гранта“ пароходы Англиянең көнчыгыш яры тирәсендә минага бәрелеп батты. Команда коткарылды.

ЛОНДОН, 12 гыйнвар. „Дейли экспресс“ газетасы, Канар атаулары тирәсендә Англиянең „Авила стар“ пароходына Германиянең 3 су асты көймәсе тарафыннан атака ясалганлыкны хәбәр итә. Англия пароходы пушкалардан ут ачкан. Су асты көймәләренең берсе зарарланган, ә калган икесе качкан.

БРЮССЕЛЬ, 12 гыйнвар. 9 нчы гыйнварга Англиянең контроль портларында нейтраль илләрнең 49 карабы булган. Шуларның 22 се Голландиянеке, 10 сы Норвегиянеке, 6 сы Швециянеке, 5 се Бельгиянеке, 2 се Даниянеке, 2 се Панаманыкы, берсе Италиянеке һәм берсе Американыкы. Бер атна эчендә—гыйнварның 1 еннән 6 сына кадәр Англия контроле 105 карабның йөкләрен карап чыккан.

Англиядә сугышка каршы хәрәкәт

ЛОНДОН, 11 гыйнвар. (ТАСС). Үзәк Саутваркта (көньяк Лондон) парламентка өстәмә сайлауларда лейборист Сирсонның кандидатурасы куелды. Сирсон сугышка каршы чыгышлар ясый. Бу кандидатураны яклаучы оешмалар арасында Кипр атавы кешеләре группасы да бар. Алар үзләренең кандидат исменә язган хатларында болай диләр:—Сугышның демократия интереслары өчен алып барылуын күрсәтү теләге белән җәелдерелә торган пропагандага карамастан, Кипрда (колониядә) губернатор „халык интересларына каршы килүче декрет ярдәме белән идарә итә. „Халыкның куркынычсызлыгына зарар китерүдә“ шикләнелгән кешеләрне кулга алу, тоту һәм судсыз сак астына алу турында полициягә хокук бирелде. Англия матбугаты һәм „социалистлар“ дип йөртелә торган кешеләр иң эре империалистик дәүләтләр тарафыннан ярдәм ала торган Маннергейм Финляндиясенең „хокуклары бозылу“ турында акрыналар. Хатта,—„Ни өчен соң алар Кипр атавы турында дәшмиләр?“ диелә.

НЬЮ-ЙОРК, 11 гыйнвар. (ТАСС). „Нью-Йорк Таймс“ газетасының Эдинбургтан (Шотландия) алып хәбәр итүенә караганда, эчке эшләр һәм эчке куркынычсызлык министре Андерсон Шотландиянең тынычлык өчен көрәш алып баручы хатын-кыз оешмалары вәкилләреннән күп санда телеграммалар ала. Алар бу телеграммаларында сугышны туктатуны таләп итәләр.

ЛОНДОН, 11 гыйнвар. (ТАСС). „Дейли Уоркер“ газетасының хәбәр итүенә караганда, тредюнионнарның Шотландия конгрессы Глазгода, Эдинбургта һәм Абердинда транспорт эшчеләренең профсоюз оешмаларына членлык взносларын үз профсоветларына түләүне туктатырга кушкан, чөнки ул профсоветлар сугышка каршы резолюцияләр кабул иткәннәр. Газета бу карарны хәзерге империалистик сугышта конгрессның позициясен кискен рәвештә гаепләүче профсоветларга каршы конгресс лидерларының ачыктан-ачык походы дип саный.

ЛЕНИН КӨННӘРЕНӘ ХӘЗЕРЛЕК

Ленин исемендәге Үзәк китапханәдә

Бөтен дөнья пролетариатының даһи юлбашчысы Владимир Ильич Ленинның үлүенә 16 ел тулу көненә В. И. Ленин исемендәге Үзәк китапханә күргәзмә хәзерли. Анда Ильичның китапханәдә булган әсәрләре һәм Ленин турында чыккан күп кенә художество һәм политик әдәбият куела. Күргәзмә тематик итеп оештырыла һәм фото-рәсемнәр, плакатлар белән бизәлә.

Китапханәнең библиография бүлеге В. И. Ленин турындагы әдәбияттан тәкъдим исемлекләре төзеде. Бу исемлекләр шәһәр китапханәләренә җибәрелделәр инде.

21 нче гыйнварда китапханә работникларының В. И. Ленинне искә алуга багышланган җыелышы үткәрелә. Стена газетасының Ленин номерын чыгаруга хәзерлек алып барыла.

Радио тапшырулар

Татарстан Радиокомитеты В. И. Ленин көннәрендә булачак тапшыруларның планын төзеде.

19 һәм 20 нче гыйнварда „Художество әдәбиятында Ленин образы“ дигән темада (чуваш телендә) чуваш совет язучыларының һәм шагыйрьләренең әсәрләре тапшырылачак. Көндез „Ленин юлыннан, Сталин җитәкчелегендә, Ленинсез 16 ел“ дигән темада беседа һәм Татарстан Совет язучылары һәм шагыйрьләренең Ленинга багышлап язылган әсәрләрен рус телендә тапшыру булачак.

21 нче гыйнварда, Ленин үлгән көнне „СССР да Ленин эше җиңде һәм ул барлык илләрдә дә җиңәчәк“ дигән темада беседа, көндез балалар өчен әдәби тапшыру, аннан соң Казандагы Ленин музей-йортыннан трансляция биреләчәк. Кичен Владимир Ильичны искә алуга багышланган зур концерт тапшырыла. Концертта Татарстанның атказанган артисткасы Зөләйха Әхметова җитәкчелегендәге татар җырлары һәм биюләре ансамбле һәм Татарстан Радиокомитеты артистлары катнашы белән Ленин—Сталин турында музыкаль һәм әдәби номерлар башкарылачак.

22 нче гыйнварда пионерлар һәм мәктәп балалары өчен тапшыру билгеләнә. Кич белән балалар язучылары һәм яшь язучылар микрофон алдында чыгачаклар. Кич 20 сәгаттә татар шагыйрьләренең Ленин турындагы әсәрләреннән әдәби тапшыру биреләчәк.

Чистайда Ленинга багышланган күргәзмәләр

Чистай шәһәренең предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә Ленин көннәренә хәзерлек бара. Парткабинетта, укытучылар йортында, судноларга ремонт ясау заводы клубында, урта мәктәптә Владимир Ильич Ленинның тормышына һәм эшенә багышланган фотокүргәзмәләр хәзерләнә.

Шәһәр предприятиеләрендә һәм колхозларда докладлар үткәрү өчен ВКП(б) райкомы 50 докладчы билгеләде. 4 нче номерлы тулы булмаган урта мәктәптә укучылар өчен „В. И. Ленин ничек укыды һәм яшәде“ дигән темада доклад үткәрүгә хәзерлек бара.

ЛЕНИНО АВЫЛЫНА ЧАҢГЫ ПОХОДЫ

Казан мехкомбинатының комсомол комитеты, комбинатның физкультура оешмалары белән берлектә, 20 нче гыйнварда Ленин музеенә (Ленино авылы) экскурсия оештыра. Экскурсиягә 15 кеше катнашып, алар Ленино авылына чаңгыларда барачаклар.

Кукмара район яшьләре хәрби эшне өйрәнәләр. РӘСЕМДӘ: сулдан уңга—хәрби өйрәнү пунктының отличникларыннан Х. Файзуллин, Т. Галимов һәм Г. Ильясов иптәшләр.
А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ВУЗ—ОБОРОНА КРЕПОСТЫ

Казан Авыл Хуҗалыгы институтының Осоавиахим оешмасы, 1938 нче ел белән чагыштырганда, 1939 нчы елны 150 процент үсте. Оборона значокларына норма тапшыручылар саны 4 тапкыр үсте. Хәзер институтта 197 „Ворошиловча атучы“, 133 „ПВХО“ значкистлары исәпләнә, пулеметчиклар, радистлар, мотоциклистлар, очучылык эшенә производстводан аерылмыйча өйрәнгән очучылар бар. Хәзер 80 нән артык кеше оборона значокларына норма тапшырырга хәзерләнә.

Оборона эшенә ВКП(б) членнары һәм кандидатлары актив катнашалар. Институтның партия оешмасында учетта торучы барлык коммунистлар да Осоавиахим членнары. Алар барсы да оборона түгәрәкләренә йөриләр. Коммунистлардан Кочкин, Несмелов, Шишенков, Вершинин һәм башка иптәшләр дүртәр оборона значогына норма тапшырдылар. Коммунист иптәш Майоровның 7 оборона значогы бар. Коммунистлардан 18 кеше станковый һәм кул пулеметларын үзләштерделәр.

Партия оешмасы институттагы барлык студентларны, укытучыларны, эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне оборона-масса эшенә тарту өчен көрәшә. (ТатТАСС).

Шәһәр елкасында 7 меңнән артык бала катнашты

Пионерлар һәм Мәктәп Балалары йортында оештырылган шәһәр елкасы бик күңелле үтте. 31 нче декабрьдән 11 нче гыйнварга кадәр елка кичәләрендә 7 меңнән артык укучы бала катнашты. Һәр көнне елка янында ике сеанс бирелде. Елка кичәләрендә Татарстан Дәүләт филармониясе, Татар Дәүләт Опера театры һәм Зур Драма театры артистлары тарафыннан концертлар бирелде. Шулай ук Пионерлар һәм Мәктәп Балалары йортының үзешчәнлек сәнгате көчләреннән дә чыгышлар оештырылды.

Балаларга бик күп санда елка бүләкләре өләшенде.

Укучы балаларның эшләреннән күргәзмә

Юдинодагы 2 нче номерлы урта мәктәп бинасында укучы балаларның эшләреннән район күләмендә күргәзмә ачылды. Районның үрнәк мәктәпләре күргәзмәгә күп төрле экспонатлар куйдылар. Бу экспонатлар мәктәп балаларының иҗад инициативаларын чагылдыра.

Мәктәпнең бер бүлмәсендә Васильево урта мәктәбе укучыларының эшләре куелган. Мондагы экспонатлар арасында „Бөек Сталинның тормышы һәм эше“ һәм „Мәктәптә оборона эшләре“ дигән альбомнар, алар белән янәшә укучыларның матур язу дәфтәрләре һәм башкалар бар.

Аракчино башлангыч мәктәбе (мөдире орденлы О. Н. Матвеева) экспонатлары бүлмәсендә яшь художникларның картиналары куелган. 4 нче класс укучысы Юзликеевнең „Җәйге пейзаж“ рәсеме караучыларны аеруча үзенә тарта.

ГАЗЕТАЛАРДАН

ВОЛГА ҖЫРЧЫСЫ ТУРЫНДА КИТАП

Куйбышевиздат XIX нчы йөздә Сембер (хәзерге Ульяновск) шәһәрендә яшәгән шагыйрь Д. Н. Садовников турында „Волга җырчысы“ дигән китапны басарга бирде. Бу китапка шулай ук шагыйрьнең үз шигырьләре дә кертелде.

Д. Н. Садовников Степан Разин турындагы атаклы рус җырының авторы. Китапны В. Крупянская төзеде һәм Академик Ю. Соколов редакциясендә чыга.

„Волжская Коммуна“.

КӘГАЗЬДӘН КОЕЛГАН САВЫТЛАР

Азык промышленностының 4 зур предприятиесе янында кәгазьдән савытлар коюю производствосы оештырылды. Главсольнең Славянскидагы заводы коелган савытларны берничә төрдә—100 грамм һәм бер килограмм сыешлы цилиндр формасындагы коробкалар, шулай ук 10—19 килограммлы ящикләр эшләп чыгара. Кәгазьдән савытлар кою цехы октябрь аенда йөз грамм сыешлы 4,5 миллион данә, килограммлы 60 мең данә коробкалар һәм 12 мең кәгазь ящикләр эшләп чыгарды.

Бабаев исемендәге Москва кондитер фабрикасында да кәгазьдән банкалар кою үткән елгы 350 мең данәдән 500 мең данәгә арттырылды. „Рот Фронт“ кондитер фабрикасы якын көннәрдә 3 килограмм сыешлы итеп кәгазьдән коелган банкалар чыгара башлый. 1940 нчы елда һәр сменада шундый 9 мең данә банка хәзерләнәчәк.

„Советская Торговля“.

ЧУВАШ ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ЯҢА ӘСӘРЛӘРЕ

Чувашстан җәмәгатьчелеге чуваш әдәбияты классигы һәм чуваш әдәби теле тудыручы К. В. Ивановның туууына 50 ел тулу көненә хәзерләнә. Танылган чуваш язучысы Яков Ухсай күптән түгел К. В. Ивановның тормышы һәм эше турында 5 пәрдәлек трагедия язып бетерде. Чуваш драматургы Александр Калган гражданнар сугышы чорыннан алып „Алим“ дигән пьеса язды. Бу пьеса Чувашстанның яшь тамашачылар театрында куелачак.

Шулай ук чуваш шагыйрьләреннән В. Услинең „Шатлык“, Ив. Ивникнең „Лирика“ һәм И. Малганның „Чык“ дигән җыентыклары басылып чыкты.

„Красная Чувашия“.

Казак художниклары һәм скульпторлары әсәрләренең күргәзмәсе

Алма-Атада Казагыстан художниклары һәм скульпторлары әсәрләренең күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәгә 250 гә якын төрле экспонат куелды. Алар арасында художникларның Казагыстанның XX еллык юбилеена багышланып эшләнгән әсәрләре һәм башкалар бар. Күргәзмә графика, сынлы сәнгать һәм скульптура бүлекләреннән тора.

СОВЕТ ХИМИКЛАРЫНЫҢ КЫЙММӘТЛЕ УЙЛАП ТАБУЛАРЫ

Харьков Химия-Технология институтының профессоры, УССР Верховный Советы депутаты Карпухин җитәкчелегендәге буяулар кафедрасы элек чит илләрдән кертелә торган кайбер буяуларның рецептураларын эшләде. Доцент иптәш Ратникова ал төстәге буяуның рецептын тапты. Сынап караулар бу буяуның сыйфаты чит илләрнекенә караганда да өстенрәк булуын күрсәтте. Тәҗрибә мастерскоенда бу рецепт буенча 3 тонна буяу хәзерләнде инде. Шулай ук ачык аранжевый төстәге буяуның да рецепты сыналып каралды.

„Легкая Индустрия“

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КАЗАН ПРОМЫШЛЕННЫЙ БАНК ТЕХНИКУМЫ
1 нче КУРСКА УКУЧЫЛАР АЛА
Техникум төзелешләргә акча җибәрү һәм контрольлек итү эшләре буенча кредит
— инспекторлары хәзерли —
УКУ СРОГЫ—3 ел.
Техникумга 15 тән 30 га кадәр яшьтә булган һәм тулы булмаган урта (7 еллык) мәктәпне тәгәлләгән барлык гражданнар алыналар.
Техникумга керүчеләр шушы ел 20 нче гыйнвардан 1 нче февральгә кадәр, тулы булмаган урта мәктәп программасы күләмендә рус теленнән һәм әдәбиятыннан, математикадан (арифметика, алгебра һәм геометрия), географиядән һәм СССР Конституциясеннән сынаулар үтәләр.
Тулы булмаган урта мәктәпне төп предметлар буенча „отлично“ билгесе белән тәгәлләүчеләр техникумга сынаусыз алыналар. Укулар шушы ел 1 нче февральдә башлана.
Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, яше һәм тулы булмаган урта мәктәпне тәгәлләү турында документлар, сәламәтлеге турында медицина белешмәсе, һәрберсенә керүченең имзасы куелган һәм дәүләт учреждениесе тарафыннан расланган ике данә фотокарточка бирелергә тиеш.
Гаризалар шушы ел 20 нче гыйнварга кадәр алына.
Техникумга алынганнарга гомуми нигездә стипендия һәм тулай торакта урын бирелә.
Казан, Карл Маркс урамы, 43. Промбанк техникумы. 27—3—2

Игътибар итегез!
Главмясосбыт Татарстан конторасы
карамагындагы
ЗАКУСОЧНАЯ
иттән хәзерләнгән һәр төрле порцияле кайнар ашлар, шулай ук, күбәйтелгән порцияле ПИЛЬМӘННӘР һәм СОЛЯНКАЛАР хәзерли. Килүчеләргә хезмәт күрсәтүдән тыш, ашлар чикләнмәгән күләмдә өйгә дә җибәрелә. Ашлар югары сыйфатлы продукциядән хәзерләнә һәм бәяләре дә югары түгел.
Адрес: Бауман урамы, 33.
2495—3—2

Главлесосбыт Казан конторасының
ЛЕСОБРАКЕРАЖ КОНТОРАСЫ,
расланган бәяләрдән, һәр төрле
агач материалларына
—экспертиза үткәрә—
Казан, Колхоз урамы, 13. Телефон 13—65.
46—2—2

КОЛХОЗЛАР ИГЪТИБАРЫНА!
1939 нчы ел ноябрь аенда Татарстан АССР колхозларына, 1940 нчы елда колхозларда учет һәм хисапчылык эшләре өчен кирәкле кенәгәләр, бланклар комплекты һәм аларның бәясе күрсәтелгән почта переводы бланклары җибәрелгән иде.
Колхозларда учет һәм хисапчылык эшләре өчен кенәгәләр һәм бланклар комплектын күрсәткән бланклар алмаган колхозлар, ул бланкларны район җир бүлегеннән ала алалар.
Учет һәм хисапчылык эшләре формаларын алдыру өчен вактында подписка бирергә тәкъдим ителә.
Союзоргучетның Татарстан бүлеге.
2674—2—2

Казгорхлебторгка даими эшкә ЭКОНОМИСТЛАР, КАССИРЛАР, хуҗалык исәбендәге магазиннарда эшләү өчен БУХГАЛТЕРЛАР һәм ПРИЛАВКА РАБОТНИКЛАРЫ кирәк. Шартлары турында белешү өчен адрес: Казан, Банк урамы, 7. Иртән 9 сәгаттән көндез 3 сәгать 30 минутка кадәр килергә. 50—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 14 нче гыйнварда (талон 96)
КЫЮ КЫЗЛАР
15 һәм 16 нчы гыйнварда спектакльләр булмый.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Тулысынча яңа программа
Москва 4 нче труппасының
— гастрольләре —
Бөтен труппа катнаша.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
15 нче гыйнварда (талон 63)
КАЧКЫН
Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
11 нче гыйнварда алган билетлар белән дә кертелә.
Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына.
Телефоннар: 29—04 һәм 30—78.

Район газеталарының һәм фабрика-завод газеталарының редакторлары, рабкорлар, селькорлар, военкорлар һәм стенгазета редколлегиясенең членнары игътибарына.
„Правда“ газетасы тарафыннан чыгарыла торган
„Рабоче-крестьянский корреспондент“ журналына
1940 нчы ел өчен шушы ел 17 нче гыйнварга кадәр
ПОДПИСКА АЛУ ДӘВАМ ИТӘ
Журнал айга ике тапкыр чыга.
Язылу бәясе: 1 айга 1 сум 20 тиен.
3 „ 3 „ 60 „
6 „ 7 „ 20 „
12 „ 14 „ 40 „
Подпискалар „Союзпечать“ тә һәм барлык почта бүлекләрендә алына. „Союзпечать“.
63—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
14, 15 һәм 16 нчы гыйнварда М. Ю. Лермонтовның туууына 125 ел тулуга багышланган юбилей спектакльләре
МАСКАРАД
Бүген талон 76.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тракторчылар
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	Көндезге сеансларда МИТЬКА ЛЕЛЮК, Кич УКЫТУЧЫ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ҺАВА ПОЧТАСЫ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндезге һәм Кичке сеансларда СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН
„РОТ-ФРОНТ“ 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	Бөек бүләк
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (беренче сериясе)

ЗВЕРИНЕЦКА
Ашыгыч рәвештә,
ШУШЫ КӨННӘРДӘ ГЕНӘ
(3—4 көн чамасында)
БАЛАЛАГАН ЭТ КИРӘК
Нинди нәселдән булса да ярый.
Телефон 31—29. 1—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 209 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 175.